**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

2021 ел, 5 июль №55

**Җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне (вәкаләтләрнең бер өлешен) Апас муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең вәкиллекле органнары Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башкарма комитетына төзекләндерү өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең башкарма комитетларына түбәндәге вәкаләтләрне тапшыру турында тәкъдимнәрен кабул итәргә:

җирлек территориясендә җир эшләрен башкарырга рөхсәт бирү;

җирлек территориясендә тышкы мәгълүмат чараларын (паспортны) урнаштыру проектын килештерү.

2.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башкарма комитетына:

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы җирлекләренең башкарма комитетлары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында типлаштырылган формага туры китереп килешүләрнең гамәлдә булуы 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагылуын исәпкә алып килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 елларның планлы чорына Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тәкъдим итәргә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru).бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының төзелеш, төзекләндерү, торак-коммуналь хуҗалык һәм инфраструктура үсеше комиссиясенә йөкләргә.

**Апас муниципаль районы**
**Башлыгы**
**Апас муниципаль районы**
**Советы рәисе** **Хисамутдинов Р.Ф.**